**Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы**
**«Туймәт авыл җирлеге»**
**муниципаль берәмлеге гражданнары җыены**
**КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Туймәт авыл җирлегенең
Туймәт торак пунктында
гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

17 октябрь 2025 ел № 1

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45,69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2025 елның 17 октябрендә киләсе мәсьәлә буенча үткәрелгән гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде: «2026 елда Чирмешән муниципаль районы Туймәт авыл җирлеге территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә, I төркем инвалидлардан, 90 яшьтән өлкәнрәк гражданнардан, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләре сафларында хезмәт итүчеләрдән, Луганск халык республикасында һәм Донецк халык республикасында махсус операциядә булган затлардан тыш һәм алынган чараларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә җибәрү белән килешәсезме:

**- торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү** (юл кырыйларын чабу, ягулык-майлау материаллары һәм триммер өчен запас частьләр сатып алу һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү, юлларны грейдерлау, кышкы вакытта урамнарны кардан чистарту, ягулык-майлау материаллары, трактор өчен запас частьләр сатып алу, Туймәт торак пунктында тракторчыга исәпләнгән хезмәт хакы, МТЗ-82 тракторы өчен асылмалы кар җыю техникасы сатып алу, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәт күрсәтүләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу,

**- урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм җиһазларның электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен башка билгеләнештәге җиһазларны ремонтлау** (Туймәт торак пунктында урам яктырткычларын монтажлау, ремонтлау, алмаштыру);

«РИЗА» «КАРШЫ».

Халык җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенының 352 катнашучысы кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 186 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен гражданнар җыенының 186 катнашучысы тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен беркем дә тавыш бирмәде.

Бәян ителгәннәр нигезендә халык җыены карар кылды:

1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Туймәт авыл җирлеге составына керүче Туймәт авылы торак пунктында халык җыены булып узган, халык җыены нәтиҗәләре - чын дип таныргa.

2. Киләсе мәсьәлә буенча: «2026 елда Чирмешән муниципаль районы Туймәт авыл җирлеге территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә, I төркем инвалидлардан, 90 яшьтән өлкәнрәк гражданнардан, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләре сафларында хезмәт итүчеләрдән, Луганск халык республикасы һәм Донецк халык республикасы махсус операциясендә булган затлардан тыш һәм алынган чараларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә җибәрү белән килешәсезме:

**- торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү** (юл кырыйларын чабу, ягулык-майлау материаллары һәм триммер өчен запас частьләр сатып алу һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү, юлларны грейдерлау, кышкы вакытта урамнарны кардан чистарту, ягулык-майлау материаллары, трактор өчен запас частьләр сатып алу, Туймәт торак пунктында тракторчыга исәпләнгән хезмәт хакы, МТЗ-82 тракторы өчен асылмалы кар җыю техникасы сатып алу, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәт күрсәтүләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу,

**- урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм җиһазларның электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен башка билгеләнештәге җиһазларны ремонтлау** (Туймәт торак пунктында урам яктырткычларын монтажлау, ремонтлау, алмаштыру);

3. Җыен нәтиҗәләрен мәгълүмати стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә: Туймәт авылы, Мәктәп ур., 4 нче йорт Чирмешән муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә рәсми интернет сайтында бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

**Гражданнар җыенында рәислек итүче**
**Татарстан Республикасы**
**Чирмешән муниципаль районы**
**Туймәт авыл җирлеге башлыгы И.В. Мортазин**